| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.09.2022 г. Казань № 619/2022

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә салу чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсесенең 2022 елның 14 сентябрендәге 26-ПР утырышы беркетмәсе нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләр расларга.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча комитетының «Татарстан Республикасы кулланучыларына сатыла торган каты ягулыкка бәяләрне исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2009 елның 10 апрелендәге 50 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу боерык аны рәсми бастырып чыгарган көннән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары Л.В.Хәбибуллинага йөкләргә.

Рәисе А.С. Груничев

Кушымта
Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.09.2022 №619/2022 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләр**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча әлеге методик күрсәтмәләр (алга таба – Методик күрсәтмәләр) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә салу чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары нигезендә эшләнде.

1.2. Бу Методик күрсәтмәләрдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

Каты ягулык, көнкүреш мич ягулыгы – таш күмер һәм агач материалы (утын) сыйфатындагы ягулык (алга таба – ягулык).

Кулланучы – Татарстан Республикасы территориясендә аларга ягулык сатыла торган гражданин, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешма, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы.

Җайга салынулы оешма – Татарстан Республикасындагы кулланучыларга ягулык сату буенча җайга салына торган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы, оешу-хокук формасына бәйсез рәвештә юридик зат яки шәхси эшкуар.

Җайга салу чоры – ягулыкка җайга салынулы бәяләр (тарифлар) (алга таба – ягулык бәяләре) билгеләнә торган кимендә бер ел дәвам иткән чор.

Алдагы чор – көйләү чорына кадәрге вакыт аралыгы.

Төп чор – көйләү чорына кадәрге календарь елы.

Төп чор күрсәткечләре – узган ел өчен хакыйкый хисап белешмәләре.

Алдагы чор күрсәткечләре – җайга салу чорына кадәрге елның агымдагы күрсәткечләре буенча көтелә торган күрсәткечләр.

1.3. Методик күрсәтмәләр Татарстан Республикасы кулланучыларына сатыла торган ягулык бәяләрен исәпләүнең төп нигезләмәләрен билгели һәм Татарстан

Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты, җайга салу органы) һәм җайга салынулы оешмалар тарафыннан файдалану өчен билгеләнә.

1.4. Методик күрсәтмәләр түбәндәге максатларда эшләнде:

кулланучыларга сатыла торган ягулык бәяләрен икътисадый нигезләүне тәэмин итү;

җайга салынулы оешмалар һәм кулланучылар мәнфәгатьләре балансына ирешү;

кулланучылар өчен ягулык бәяләренең түли алырлык булуын тәэмин итү һәм аларның мәнфәгатьләрен бәяләрне нигезсез үзгәртүдән саклау.

## 2. Татарстан Республикасы кулланучыларына сатыла торган ягулыкка бәяләрне формалаштыру буенча төп методик нигезләмәләр

2.1. Дәүләт комитеты җайга салынулы оешма өчен Татарстан Республикасы кулланучыларына сатыла торган ягулыкка максималь дәрәҗәдә чик бәяне билгели.

Ягулык бәяләре үлчәү берәмлеге өчен сумнарда билгеләнә һәм ягулык төренә (күмер яки утын) карап дифференциацияләнә:

күмер өчен иң чик максималь бәя (тариф) бер тонна күмер өчен сумнарда билгеләнә;

утынга максималь бәя (тариф) бер тыгыз куб метр утын өчен сумнарда билгеләнә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (муниципаль район, шәһәр округы, шәһәр (авыл) җирлеге) буенча бердәм).

Ягулык өчен иң чик максималь бәяләр Татарстан Республикасы территориясендә халыкка ягулык сатучы барлык оешмалар тарафыннан, милекнең оештыру-хокукый рәвешләренә һәм формаларына бәйсез рәвештә, шулай ук хосусый эшкуарлар тарафыннан кулланыла.

2.2. Ягулык бәяләрен билгеләү ягулыкка җайга салына торган бәяләр билгеләнә торган ким дигәндә бер ел дәвам иткән чорга гамәлгә ашырыла.

2.3. Ягулык бәйләрен җайга салганда Дәүләт комитеты тарафыннан түбәндәгеләр кулланылырга мөмкин:

икътисадый нигезләнгән чыгымнар (сарыфлар) алымы;

бәяләрне индексацияләү ысулы;

аналогларны чагыштыру ысулы.

2.4. Икътисадый нигезләнгән чыгымнар ысулын кулланганда җайга салынулы бәяләр җайга салынулы оешмаларның зыянсыз эшчәнлеге өчен кирәкле минималь чыгымнарны каплауны тәэмин итүче күләмнәрдә билгеләнә.

2.5. Ягулык бәяләрен исәпләү өчен кулланылган чыгымнар составын билгеләү һәм аларның дөреслеген бәяләү Россия Федерациясе Салым кодексының 25 бүлеге , башка норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.6. Ягулык бәяләрен исәпләү җайга салынулы эшчәнлек алып баручы оешмалар тарафыннан җайга салынулы эшчәнлеккә карата керемнәрне һәм чыгымнарны аерым исәпкә алуны алып бару мәҗбүрилеге принцибына нигезләнә.

2.7. Ягулык бәяләре, алгоритм ярдәмендә башкарыла торган эшләрнең технологиясен исәпкә алып, берәмлекнең үзкыйммәтенә фактик чыгымнарны турыдан-туры кертү хисабына исәпләнә.

Элек бу өлкәдә эшчәнлек башкармаган һәм чыгымнар буенча фактларгы белешмәләре булмаган оешмалар өчен бәяләрне исәпләгәндә, исәп-хисап аларның эшчәнлегенең планлаштырылган күрсәткечләре нигезендә башкарыла. Мондый оешмалар өчен планлаштырыла торган эшчәнлек күрсәткечләре шундый ук эшчәнлек алып баручы оешмалар чыгымнары белән чагыштырма анализны исәпкә алып кабул ителә.

2.8. Ягулык бәяләрен исәпләгәндә хезмәт өчен түләү чыгымнары тиешле оешмалар (алар булган очракта), күмәк шартнамәләр, башка норматив хокукый актлар белән төзелгән тармак тариф килешүләрен исәпкә алып билгеләнә.

2.9. Ягулык әзерләүгә турыдан-туры карамаган оешманың чыгымнары (гомуми хуҗалык чыгымнары, башка чыгымнар) турыдан-туры чыгымнарга пропорциональ рәвештә хезмәт күрсәтү төрләре арасында бүленә.

2.10. Әзерләү һәм җиткерү шартларына карап, ягулык бәясенә әзерләү, кулланучыга кадәр китереп җиткерү, җайга салына торган оешма складына бушату, складтан сатып алучы тарафыннан бирелгән транспорт чарасына (җайга салына торган оешма складында франко-транспорт чарасы) төяү чыгымнары кертелә.

3. Ягулык бәяләрен раслау буенча исәп-хисап материаллары

3.1. Ягулык бәяләрен билгеләү Дәүләт комитеты тарафыннан җайга салынулы эшчәнлек башкаручы җайга салынулы оешма инициативасы белән яисә, заказ бирүче әлеге Методик күрсәтмәләрдә каралган ягулыкка һәм (яки) материалларга бәяләр билгеләү турында гариза тапшырмаган очракта, Дәүләт комитеты инициативасы белән башкарыла.

3.2. Җайга салынулы оешма чираттагы җайга салу чорына кадәр ел саен 1 июльгә кадәр Дәүләт комитетына ягулык бәяләрен билгеләү турында тәкъдим кертә.

3.3. Җайга салынулы эшчәнлек алып баручы җайга салынулы оешма инициативасы белән ягулыкка бәяләрне билгеләү җайга салынулы оешма тарафыннан Дәүләт комитетына тапшырыла торган түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

1. Әлеге Методик күрсәтмәләргә карата 1 нче кушымта нигезендә җайга салынулы эшчәнлек башкаручы оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган бәяләрне билгеләү турында гариза.

2. Ягулык бәяләрен билгеләү (үзгәртү) кирәклеген раслаучы кыска аңлатма язуы.

3. Оештыру документларының күчермәләре.

4. Җайга салынулы эшчәнлек башкаручы оешманың исәпкә алу сәясәте һәм счетларның эш планы турында боерык күчермәләре.

5. Алдагы чорга һәм соңгы хисап датасына бухгалтерлык хисаплылыгы.

6. Әлеге Методик күрсәтмәләргә 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча ягулык сату турында белешмәләр.

7. Әлеге Методик күрсәтмәләргә 3 нче, 4 нче кушымталарда күрсәтелгән форма буенча ягулык төрләре буенча бәяләр исәпләмәсе (үзбәя калькуляциясе).

8. Ягулык сатып алу бәяләрен нигезләүче документларның күчермәләре (шартнамәләр, счет-фактуралар).

9. Үзбәя калькуляциясенә карата материаль, өстәлмә, башка төр чыгымнарның һәм чыгымнарның башка статьяларының аңлатмалары (әлеге Методик күрсәтмәләргә 5 нче, 6 нчы, 7 нче, 9 нчы кушымталарда күрсәтелгән форма буенча нигезли торган документларның күчермәләрен теркәп).

10. Хезмәт өчен түләү фонды исәпләмәсе.

11. Җайга салынулы эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган оешмада гамәлдә булган норматив һәм тармак актлары (тариф килешүе, хезмәт хакы турында нигезләмә, премияләү турында нигезләмә, коллектив шартнамә, штат расписаниесе, П-4 формасы «Хезмәткәрләрнең саны, хезмәт хакы һәм хәрәкәте турында мәгълүматлар» һ.б.).

12. Җайга салынулы эшчәнлек алып баручы оешма буенча һәм база чорында эшчеләр һәм хезмәткәрләр категорияләре буенча уртача айлык хезмәт хакы турында белешмәләр.

13. База чорында төп финанс-икътисад күрсәткечләре турында белешмә.

14. Әлеге Методик күрсәтмәләргә 10 нчы кушымтада күрсәтелгән форма буенча кирәкле табышны нигезләү.

15. База чорында табыш бүлү турында белешмә.

16. Хезмәт күрсәтүгә (җылылык һәм электр энергиясеннән файдаланган, су белән тәэмин иткән һәм ташландык суларны агызган, телефон элемтәсе хезмәте, биналарны саклау хезмәте һ.б. өчен) чит предприятиеләр (оешмалар) белән төзелгән шартнамәләрнең күчермәләре.

Кушымталарда кертелә торган таблицаларда каралмаган чыгымнар статьяларын шифрлау ирекле формада тәкъдим ителә.

Натураль күрсәткечләр узган елның тиешле чоры белән чагыштырыла, күрсәткечләр дәрәҗәсенең үзгәрүе (артуы яки кимүе) турында нигезләү бирелә.

Әлеге Методик күрсәтмәләргә кушымталарны тутырганда таблицаларда төп чорның хисап (көтелгән) күрсәткечләре күрсәтелә.

Тапшырылган документларга кул куела, ә документларның күчермәләре тиешенчә җайга салынулы оешманың вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан раслана.

Барлык материаллар да кәгазь һәм электрон медиа чыганакларында тәкъдим ителә.

Коммерция һәм серле документлар тиешле билгегә ия булырга тиеш.

## 4. Ягулык бәясен билгеләү тәртибе һәм үзенчәлекләре

4.1. Ягулык бәяләрен билгеләү һәм тапшырылган документларны һәм материалларны кире кайтару турындагы тәкъдимнәрне карап тикшерүдән баш тарту турында карар кабул итүнең нигезе булып җайга салынулы оешманың әлеге

Методик күрсәтмәләрдә билгеләнгән ягулык бәяләрен билгеләү турындагы тәкъдимне тапшыру срокларын үтәмәве, Дәүләт комитетына документлар һәм материалларның тулы булмаган күләмен тапшыруы, Татарстан Республикасы кулланучыларына ягулык сату эшчәнлеге чыгымнарын һәм җайга салынулы оешманың эшчәнлекнең башка төрләренә чыгымнарны аерым исәпкә алып бармавы тора.

Ягулык бәяләрен билгеләү турындагы тәкъдимнәрне караудан баш тарту һәм тапшырылган документларны һәм материалларны кире кайтару турында карарны башка нигезләрдә кабул итү рөхсәт ителми.

4.2. Эшне ачу яисә җайга салынулы оешма тарафыннан тапшырылган документларны һәм материалларны кире кайтарып, ягулык бәясен билгеләү турындагы тәкъдимнәрне караудан баш тарту ягулык бәясен билгеләү турындагы гаризаны теркәгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Дәүләт комитетының ягулык бәяләрен билгеләү турында тәкъдимнәрне карау турында эш ачу яки эш ачудан баш тарту турындагы карары заказлы почта юлламасы белән яисә электрон рәвештә, шул исәптән «Федераль җайга салу органы – төбәк җайга салу органнары – җайга салу субъектлары» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша, ягулык бәяләрен билгеләү турындагы тәкъдимнәрне карау турында эш ачу яки эш ачудан баш тарту турында карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне эчендә, заказлы почта аша җибәрелә.

Ягулык бәяләрен билгеләү турында тәкъдимнәрне караудан баш тарту законнарда һәм әлеге Методик күрсәтмәләрдә каралган тәртиптә тәкъдимнәрне караудан баш тарту өчен нигез булган сәбәпләрне бетергәннән соң җайга салу органына кабат мөрәҗәгать итү өчен киртә булып тормый.

Җайга салынулы оешмалар тарафыннан ягулык бәяләрен билгеләү турында тапшырылган тәкъдимнәрне анализлау барышында ягулык бәяләрен билгеләү турындагы тәкъдимнәрне тәгаенләштерү зарурлыгы барлыкка килсә, җайга салу органы өстәмә белешмәләр соратып ала, шул исәптән җайга салынулы оешма тарафыннан алдагы җайга салу чорында фактта тотылган чыгымнарны раслый торганнарын да. Мондый мәгълүматларны тапшыру срогы җайга салу органы тарафыннан билгеләнә, ләкин җайга салынулы оешмага таләп алынган көннән башлап 7 эш көненнән дә ким булмаска тиеш.

4.3. Тариф эшләренә анализ үткәрү нәтиҗәләре буенча ягулык бәясен билгеләүгә эксперт бәяләмәсе һәм ягулык бәясен билгеләү турында Дәүләт комитеты карары проекты әзерләнә.

Ягулык бәясен билгеләү турындагы карар проекты Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, иҗтимагый оешмалар һәм Татарстан Республикасы буенча дәүләт хакимияте федераль органнарының территориаль органнары вәкилләре катнашында Каршылыклы карашлар буенча комиссия утырышында карала.

4.4. Ягулык бәясен билгеләү турында карар Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышында кабул ителә.

4.5. Ягулык бәясе Дәүләт комитеты тарафыннан чираттагы җайга салу чоры башланганчыга кадәр, ләкин чираттагы җайга салу чоры башланганчы, әлеге Методик күрсәтмәләр нигезендә, 20 декабрьдән дә соңга калмыйча билгеләнә.

4.6. Дәүләт комитеты инициативасы белән ягулык бәясен билгеләү Дәүләт комитеты тарафыннан җайга салынулы оешмадан Дәүләт комитетының мотивацияләнгән таләбе буенча алынган материаллар нигезендә һәм әлеге Методик күрсәтмәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Ягулык бәяләрен яңадан карау өчен нигезләр

5.1. Ягулык бәясен яңадан карау Дәүләт комитеты тарафыннан түбәндәге нигезләрнең берсе булганда башкарыла:

җайга салынулы оешмаларның алдагы хисап чорына бәяләрне исәпләгәндә кабул ителгән чыгымнар белән чагыштырганда җайга салынулы эшчәнлекне тормышка ашыруга суммар чыгымнарының үзгәрүе;

Дәүләт комитеты тарафыннан җайга салынулы эшчәнлек алып баручы җайга салынулы оешмаларның хуҗалык эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре;

ягулык бәясен билгеләү турында элегрәк кабул ителгән карарларны Россия Федерациясе законнарына туры китерү;

җайга салу чоры дәвамында җайга салынулы оешманың салым салу системасын җайга салудагы үзгәрешләр;

ягулык бәясен яңадан карау зарурлыгын күздә тота торган законлы көченә кергән суд карары;

ягулык бәясен яңадан карау кирәклеген күздә тоткан ягулык бәясен җайга салу буенча федераль орган карары яки боерыгы.

## 6. Икътисадый нигезләнгән чыгымнар (сарыфлар) ысулы белән ягулык бәяләрен исәпләү тәртибе

6.1. Кулланучылар сатып ала торган ягулык бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Ц = С + П,$$

биредә:

С – ягулык берәмлегенең үзкыйммәте;

П – кирәкле табыш (рентабельлек).

6.2. Ягулык (күмер) берәмлегенең бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$С = Зз + Зтр + Зпхп + Зн + Зд,$$

биредә:

Зз – сатып алу бәясе (әзерләү бәясе) буенча ягулык бәясе;

Зтр – ягулыкны җайга салынулы оешмага кадәр китертү хезмәтләренең бәясе;

Зпхп – ягулыкны эшкәртү (бушату, урынын алмаштыру, складка урнаштыру), саклау һәм төяү чыгымнары;

Зн – өстәлмә чыгымнар;

Зд – ягулыкны кулланучыга кадәр китерү буенча 10 км өчен хезмәт күрсәтү бәясе.

6.3. Ягулык (утын) берәмлегенең бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$С = Зопл + Ззл + Зоэр + Зд,$$

биредә:

Зопл – урман атламасы өчен түләү чыгымнары (агач кисү өчен түләү);

Ззл – урман әзерләү чыгымнары (әлеге Методик күрсәтмәләргә 3 нче кушымта буенча);

Зоэр –гомумэксплуатация чыгымнары;

Зд – ягулыкны кулланучыга кадәр китерү буенча 10 км өчен хезмәт күрсәтү бәясе.

6.4. Ягулык бәясенә кертелә торган табыш күләмен билгеләгәндә, җайга салынулы оешманың керем салымының салым базасын билгеләгәндә (салымнан соң табышка кертелә торган) исәпкә алынмый торган чыгымнары түбәндәге төп чыгымнарны үз эченә ала:

киңәйтелгән җитештерү өчен капитал (инвестицияләр) кертү;

салым салынганнан соң табышка кертелә торган башка икътисадый нигезләнгән чыгымнар, шул исәптән оешмаларның тармак килешүләре нигезендә эшчеләргә ташламалар, гарантияләр һәм компенсацияләр бирү чыгымнары.

7. Индексацияләү ысулы белән ягулык бәяләрен исәпләү тәртибе

7.1. Ягулык бәяләрен индексацияләү методы җайга салу чорына Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан эшләнгән Россия Федерациясен социаль-икътисадый үстерү фаразының база вариантында кулланучы бәяләренә индекс-дефляторны исәпкә алып элегрәк билгеләнгән ягулык бәяләрен индексацияләүне күздә тота.

Озак сроклы ягулык бәяләре билгеләнгәндә (1 елдан артыграк вакытка) индексацияләү методы кулланыла.

Ягулык бәяләрен индексацияләү ысулын кулланганда, тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары озак сроклы җайга салу чорының һәр елына билгеләнә.

Ягулык бәяләрен билгеләгәндә җайга салу органы ягулык сатучы җайга салынулы оешмаларның икътисадый нигезсез чыгымнары исәбеннән төшереп калдыруга юнәлдерелгән чараларны күрә.

Исәп-хисаптан алдагы җайга салу чоры йомгаклары буенча яисә контроль чараларны җайга салу органы үткәргән контрольлек чараларында статистика һәм бухгалтерлык хисаплылыгы һәм башка материаллар нигезендә җайга салынулы оешмаларның җайга салынулы эшчәнлектән кергән керемнәр исәбенә нигезсез чыгымнары булуы ачыкланса, Дәүләт комитеты әлеге чыгымнарны җайга салу чорына ягулык бәясен раслаганда исәпкә алына торган чыгымнар суммасыннан төшереп калдыра.

Дәүләт комитетына тапшырылган закон һәм әлеге Методик күрсәтмәләр нигезендә рәсмиләштерелгән, документаль расланган чыгымнар (сарыфлар) нигезле дип таныла.

## 8. Аналогларны чагыштыру ысулы белән ягулык бәяләрен исәпләү тәртибе

Аналогларны чагыштыру методы Татарстан Республикасы кулланучылары сатып ала торган ягулыкка максималь дәрәҗәдә чик бәя билгеләгәндә кулланыла.

Аналогларны чагыштыру ысулы җайга салынулы эшчәнлек башкаручы оешманың эшчәнлек күрсәткечләрен икътисадый һәм техник характеристикалар буенча башка оешмаларның охшаш күрсәткечләре белән чагыштыруга нигезләнгән.

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләргә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе
А.С.Груничевка

Җайга салынулы бәяләрне билгеләү өчен гариза

_______________________________________________өчен
ягулык төре
_______________________________________________өчен
Җайга салу чоры

Җайга салынулы оешманың исеме __________________________________________
Юридик адресы: ___________________________________________
Почта адресы: ____________________________________________________
________________________________________________________________________________
Электрон почта адресы _________________________________________________________
Оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме __________________________
Телефон, факс ____________________________________________________________________
Җаваплы башкаручының фамилиясе, исеме, атасының исеме
___________________________________________________________
Сездән _______________________өчен бәя билгеләү турында сорыйм
(каты ягулык төре)
кушымтада бирелә торган исемлек нигезендә ______елга.
Бәя билгеләү яки аны яңадан карау нигезе _____________________________________
________________________________________________________________________________
Бәяләр буенча тәкъдимнәр проекты һәм нигезләү материаллары беркетелә.
Кушымта: 1. ________________________________________________________________
(тапшырылган материаллар реестры)
2. ______________________________________________________________________

(материаллар (таблицалар) һәм дискета белән,
реестр нигезендә)

Оешма җитәкчесе_________________________________ (Ф.И.А.)

Дата

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләргә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы кулланучыларына күмер сату күләмнәре

________________________________________

(җайга салынулы оешма атамасы)

| т/с | Җайга салынулы оешманың исеме | Төп чордан алда килгән чор (факт буенча) | | | Төп чор | | | | | | Җайга салу чоры | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Исәпләмә | | | факт | | | | | |
| | | Күмер сату күләме, барлыгы, тоннада | Шул исәптән: | | Күмер сату күләме, барлыгы, тоннада | Шул исәптән: | | Күмер сату күләме, барлыгы, тоннада | Шул исәптән: | | Күмер сату күләме, барлыгы, тоннада | Шул исәптән | |
| | | | Халыкка | Башка кулланучыларга | | Халыкка | Башка кулланучыларга | | Халыкка | Башка кулланучыларга | | Халыкка | Башка кулланучыларга |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы кулланучыларына утын сату күләмнәре

________________________________

(җайга салынулы оешма атамасы)

| т/с | Учреждениенең исеме | Төп чордан алда килгән чор (факт буенча) | | | Төп чор | | | | | | Җайга салу чоры | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Исәпләмә | | факт | | | | | |
| | | Утын сату күләме, барлыгы куб.м мәйд. | Шул исәптән: | | Утын сату күләме, барлыгы куб.м мәйд. | Шул исәптән: | | Утын сату күләме, барлыгы куб.м мәйд. | Шул исәптән: | | Утын сату күләме, барлыгы куб.м мәйд. | Шул исәптән | |
| | | | Халыкка | Башка кулланучыларга | | Халыкка | Башка кулланучыларга | | Халыкка | Башка кулланучыларга | | Халыкка | Башка кулланучыларга |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләргә 3 нче кушымта

Халыкка сатыла торган ягулык бирәмлегенең бәясен (үзкыйммәт калькуляциясен) исәпләү

(бер тоннага сумнарда)

| Җайга салынулы оешманың исеме | Күрсәткеч | Төп чордан алда килгән чор (факт буенча) | Төп чор | | Җайга салу чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Исәпләмә | Хакыйкый | |
| | Ягулык сатып алу бәясе (әзерләү бәясе) | | | | |
| | Транспортлау буенча хезмәтләр күрсәтү бәясе, шул исәптән: | | | | |
| | - т/ю транспорты хезмәте күрсәтү бәясе | | | | |
| | - су транспорты хезмәте күрсәтү бәясе | | | | |
| | - автотранспорт хезмәте күрсәтү бәясе | | | | |
| | Эшкәртү, саклау һәм төяю чыгымнары | | | | |
| | Өстәлмә чыгымнар | | | | |
| | Кирәкле табыш | | | | |
| | Ягулык сату бәясе | | | | |

Искәрмә:

Өстәмә рәвештә эшкәртү, саклау һәм төяү чыгымнарын, шулай ук тулаем предприятие һәм продукция берәмлегенә өстәлмә чыгымнарны исәпләү күздә тотыла.

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләргә 4 нче кушымта

Халыкка сатыла торган ягулык (утын) берәмлегенең бәясен (үзкыйммәт калькуляциясен) исәпләү

бер тыгыз куб метр өчен

| т/с | Чыгымнарның статьялары | Төп чорга кадәр чор | Төп чор | | Җайга салу чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | исәпләмә | факт | |
| 1. | Урман атламасы өчен түләүгә чыгымнары (агач кисү өчен түләү), сум. | | | | |
| 2. | Урман әзерләү чыгымнары, сум. | | | | |
| 2.1. | Ягулык-майлау материаллары һәм запчас өлешләр, сум. | | | | |
| 2.2. | Хезмәткә түләү чыгымнары, сум. | | | | |
| 2.3. | Социаль ихтыяҗлар өчен түләүләр күчерү, сум | | | | |
| 2.4. | Башка чыгымнар, сум. | | | | |
| 2.5. | Цех чыгымнары, сум. | | | | |
| 3. | Гомуми эксплуатация чыгымнары, сум. | | | | |
| 4. | Үзкыйммәт, сум. | | | | |
| 5. | Табыш (рентабельлелек<*>), сум. | | | | |
| 6. | Өстәмә хак салымыннан башка ваклап сату бәясе, сум. | | | | |
| 7. | Өстәмә хак салымы, сум. | | | | |
| 8. | Өстәмә хак салымы белән ваклап сату бәясе, сум. | | | | |

| | |
|---|---|
| <*> | рентабельлелек проценты, % |

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләргә 5 нче кушымта

Урман атламасы өчен түләү чыгымнары (агач кисү өчен түләү);

бер тыгыз куб метр өчен

| т/с | Тәэмин итүчеләр | Төп чордан алда килгән чор (факт буенча) | | | Төп чор | | | Җайга салу чоры | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Күләме, куб.м мәйд. | Бәя, сум | Чыгымнар, сум | Күләме, куб.м мәйд. | Бәя, сум | Чыгымнар, сум | Күләм, куб.м мәйд. | Бәя, сум | Чыгымнар, сум |
| 1 | | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | җәмгысе | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләргә 6 нчы кушымта

Ягулык-майлау материаллары һәм запчас өлешләргә чыгымнар

бер тыгыз куб метр өчен

| т/с | Материаллар | Төп чордан алда килгән чор (факт буенча) | | | Исәп-хисап чоры | | | Предприятие тәкъдиме | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Күләме, куб.м мәйд. | Бәя, сум | Чыгымнар, сум | Күләм, куб.м мәйд. | Бәя, сум | Чыгымнар, сум | Күләм, куб.м мәйд. | Бәя, сум | Чыгымнар, сум |
| | ЯММ (ш.и. майлар) | | | | | | | | | |
| 1 | | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | Җәмгысе ягулык | | | | | | | | | |
| | Запас өлешләр | | | | | | | | | |
| 1 | | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| | Җәмгысе зап. өлешләр | | | | | | | | | |
| | Җәмгысе | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш мичендә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләргә 7 нче кушымта

Төп эшчеләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнары

| т/с | Вазыйфа исеме, хезмәткәрнең һөнәрләре | Исәп-хисап чоры | | | | | Предприятие тәкъдиме | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Норматив исәп | Хезмәткәрләрнең разряды | Тариф ставкасы, сум | Хезмәт хакы күләме, сум | Хезмәт хакы күләме, сум | Норматив исәп | Хезмәткәрләрнең разряды | Тариф ставкасы, сум | Хезмәт хакы күләме, сум | Хезмәт хакы күләме, сум |
| | Сәнәгый-җитештерү персоналының хезмәт хакы (ППР) | | | | | | | | | | |
| 1 | | | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| | Җәмгысе хезмәт хакы | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| | Социаль ихтыяҗлар өчен акча күчерү | | | | | | | | | | |
| 1 | | | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| | Җәмгысе социаль ихтыяҗларга акча күчерү | | | | | | | | | | |
| | Җәмгысе хезмәт өчен түләү | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | чыгымнары | | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләргә 8 нче кушымта

Башка чыгымнар

(ягулык төренә карап үлчәү берәмлеге өчен мең сум)

| т/с | Чыгымнарның статьялары | Төп чордан алда килгән чор (факт буенча) | Төп чор | | Җайга салу чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | исәпләмә | факт | |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| | | | | | |
| | җәмгысе | | | | |

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләргә 9 нчы кушымта

Гомуми җитештерү (гомумхуҗалык) чыгымнары

(ягулык төренә карап үлчәү берәмлеге өчен мең сум)

| т/с | Чыгымнарның статьялары | Төп чордан алда килгән чор (факт буенча) | Төп чор | | Җайга салу чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | исәпләмә | факт | |
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| | | | | | |
| | җәмгысе | | | | |

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш миченә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләргә 10 нчы кушымта

Ягулык бәяләрен билгеләгәндә кабул ителә торган кирәкле табышны исәплəү (мең сум)

| Атамасы | Төп чорга кадәр чор (факт буенча) | Төп чор | | Җайга салу чоры |
|---|---|---|---|---|
| | | исәпләмә | факт | |
| Җитештерүне үстерү өчен табыш | | | | |
| Социаль үсеш өчен табыш | | | | |
| Башка максатлар өчен табыш | | | | |
| Шул исәптән: | | | | |
| Салым салына торган табыш | | | | |
| Салымнар, җыемнар, түләүләр – барлыгы | | | | |
| Шул исәптән: | | | | |
| табыш өчен | | | | |
| мөлкәткә | | | | |
| пычраткыч матдәләр чыгару өчен түләүләр | | | | |
| башка салымнар, җыемнар һәм түләүләр (шифрлап) | | | | |
| Гомуми табыш суммасы | | | | |
| Җайга салынулы эшчәнлек төрләренә караган табыш | | | | |
| Шул исәптән: | | | | |
| күмер сату хисабына | | | | |
| утын сату хисабына | | | | |

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга, гражданнарның торак ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатларында булдырылган идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак, торак-төзелеш яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына сатыла торган каты ягулык, көнкүреш мичендә ягулык өчен максималь бәяләрне (тарифлар) исәпләү һәм билгеләү буенча методик күрсәтмәләргә 11 нче кушымта

Кулланучыга кадәр ягулык җибәрү хезмәтләрен исәпләү, 10 км өчен

| Атамасы | Төп чорга кадәр чор (факт буенча) | Төп чор | | Җайга салу чоры |
|---|---|---|---|---|
| | | исәпләмә | факт | |
| Кулланучыга ягулык җибәрү чыгымнары, барлыгы | | | | |
| Шул исәптән: | | | | |
| шоферларның хезмәт хакы | | | | |
| иминият кертемнәре | | | | |
| автомобиль ягулыгы | | | | |
| майлау материаллары | | | | |
| техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | | | | |
| авторезинның тузуы һәм ремонт | | | | |
| Амортизация түләүләре | | | | |
| лизинг түләүләре | | | | |
| Башка чыгымнар | | | | |
| 10 километрга җибәрү өчен уртача тариф | | | | |